РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ БОЛЬШЕКИБЯЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422065, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Большие Кибячи, ул.Ф.Энгельса, 21
тел. (84362) 42-6-24

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КИБӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422065, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Кибәче авылы, Ф.Энгельс урам, 21 йорт
тел. (84362) 42-6-24

e-mail: Bkib.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
18.02.2022

КАРАР
№3

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының 2021 нче елның 8 нче ноябрендә кабул ителгән 28 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә (алга таба – нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1.Нигезләмәнең 3 нче кушымтасын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

Авыл җирлеге башлыгы А.К. Сафин

Кушымта
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Олы Кибәче
авыл җирлеге Советының 18.02.2022
ел №3 карарына

Кушымта № 3
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Олы Кибәче
авыл җирлеге чикләрендә
муниципаль торак контроле
турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү хакында

1. Муниципаль торак контроленең төп күрсәткечләре

1 нче таблица

| Төп күрсәткечләр | Максатчан күрсәткечләр |
|---|---|
| Торак законнарын бозу очраклары ачыкланган санның бетерелгән проценты | 70% |
| Чираттагы календарь елына планлы контроль чаралар үткәрү планын үтәү проценты | 100% |
| Муниципаль контроль органы һәм (яки) аның вазыйфаи затының контроль чаралар үткәргәндә гамәлләренә (гамәл кылмавына) нигезләнгән шикаятьләрнең проценты | 0% |
| Контроль чаралар нәтиҗәләренең бетерелгән проценты | 0% |
| Административ йогынты чаралары күрелмәгән нәтиҗәле контроль чаралар проценты | 5% |
| Муниципаль контроль органы материаллары буенча административ җәза билгеләү турында суд карарлары проценты | 95% |
| Административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча суд тәртибендә юкка чыгарылган карарларның муниципаль контроль органы тарафыннан чыгарылган карарларның гомуми санынннан проценты | 0% |

2. Чаралар үткәрү параметрларын характерлаучы индикатив күрсәткечләр

2.1. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда түбәндәге индикатив күрсәткечләр билгеләнә;

1) хисап чорында үткәрелгән планнан тыш тикшерү чаралары саны;

2) контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килү-килмәүне ачыклау яисә хисап чорында контроль объектының мондый параметрлардан читләшүен ачыклау нигезендә хисап чорында үткәрелгән планнан тыш тикшерү чаралары саны;

3) хисап чорында үткәрелгән үзара хезмәттәшлек белән контроль чараларның гомуми саны:

4) хисап чорында үткәрелгән КНМНЫҢ һәр төре буенча үзара хезмәттәшлек итү буенча контроль чаралар саны:

5) хисап чорында дистанцион үзара тәэсир итешү чараларын кулланып үткәрелгән контроль чаралар саны;
6) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитларның саны;
7) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр саны;
8) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган контроль чаралар саны;
9) хисап чорында административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль чаралар саны;
10) хисап чорында контроль чаралар нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;
11) хисап чорында тикшерү чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;
12) хисап чорында прокуратура органнары тарафыннан килештерүдән баш тарткан контроль чаралар үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;
13) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;
14) хисап чоры азагына куркынычның һәр категориясе буенча куркынычлылык категориясенә кертелгән контроль объектларының исәпкә алынган объектлары саны;
15) хисап чоры ахырына контрольдә тотылучы затларның исәпкә алынган саны;
16) хисап чорында контроль чаралар үткәрелгән исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;
17) тикшерү органы тарафыннан карау срогы бозылган шикаятьләрнең хисап чорында саны;
18) контроль органнарның вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъвалау турында хисап чорында дәгъва гаризалары саны;
19) контроль органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъвалау турында алар буенча хисап чорында игълан ителгән таләпләрне канәгатьләндерү турында Карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны;
20) муниципаль контрольне оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозу белән үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яисә) хисап чорында юкка чыгарылган контроль чаралар саны.